ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында” 2015 елның 26 декабрендәге 108-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә “, авыл” сүзен төшереп калдырырга, “җир кишәрлекләре белән эш итү” сүзләрен “җир кишәрлекләрен бирү” сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 статьяда “җирдән файдалану һәм җирлектә төзелеш алып бару кагыйдәләре расланган Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләре (алга таба – шәһәр, авыл җирлекләре) җирле үзидарә органнарының дәүләт милке чикләнмәгән, шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен шәһәр, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында” сүзләрен “Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләре җирле үзидарә органнарының дәүләт милке чикләнмәгән, мондый җирлекләр территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен бирү буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләре җирле үзидарә органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә “җир кишәрлекләре белән эш итү буенча” сүзләрен “җир кишәрлекләрен бирү буенча” сүзләренә алмаштырырга;

2) преамбулада “җир кишәрлекләре белән эш итү буенча” сүзләрен “җир кишәрлекләрен бирү буенча” сүзләренә алмаштырырга;

3) 1 статьяда “муниципаль район составындагы җирдән файдалану һәм җирлек төзү алып бару кагыйдәләре расланган шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча” сүзләрен “муниципаль район составына керүче шәһәр җирлекләре территорияләрендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча” сүзләренә алмаштырырга;

4) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2 статья. **Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемнәре**

Дәүләт вәкаләтләре Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына бирелә:

Әгерҗе муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Алексеевск муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы,

Балык Бистәсе муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Сарман муниципаль районы, Спас муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы.»;

5) 4 статьяның 2 өлешендә “җир кишәрлекләре белән эш итү буенча” сүзләрен “җир кишәрлекләрен бирү буенча” сүзләренә алмаштырырга;

6) кушымтада:

а)

“Татарстан Республикасы
муниципаль районнарының
җирле үзидарә органнарына дәүләт
милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш
итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт
вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан
Республикасы Законына кушымта”

сүзләрен

“Татарстан Республикасы
муниципаль районнарының
җирле үзидарә органнарына дәүләт
милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү
буенча Татарстан Республикасы дәүләт
вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан
Республикасы Законына кушымта”

сүзләренә алмаштырырга;

б) исемендә “җир кишәрлекләре белән эш итү буенча” сүзләрен “җир кишәрлекләрен бирү буенча” сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2016 елның 28 ноябре
№ 92-ТРЗ